**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентябрь 2014 ел Казан шәһәре № 7-19/т

***Татарстан Республикасының Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны, әлеге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.

2. “Татарстан Республикасының Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында” 05.07.2012 № 7-13/т Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарының 1нче пунктын үз көчен югалткан дип исәпләргә.

3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитеты карарына
кушымта
19 сентябрь 2014 ел № 7-19/т

## Татарстан Республикасының Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм бер урын багажны алып баруга максималь чик тариф (руб.) | | |
|---|---|---|---|
| | билетны транспорт салонында алган чакта | Озак вакыт кулланулы билеты белән түләгәндә | |
| | | 1 тапкыр бару[1] | 50 тапкыр бару[2] |
| Автобус | 20 | 18 | 15 |

<1> Билгеле бер сумма кысаларында, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм;

<2> Билгеле бер вакыт аралагында билгеләнгән тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж өчен транспортта бару бәясенә өстәп түлләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге